# ГОМЕР

*(Танго)*

*Гәрәй Рәхим* сүзләре

**Tempo di tango**




16
лар - ның да жу-я ба-ра а-сыл тѳс-лә - рен. Я - ши- я-ши ин-де сү - нә ба-ра
21
яшь-лек тә-ге кай-нар хис-лә - рең. Яшь-лек-тә-ге кай-нар хис-лә - рең.
25
Ә ай шул ук ка - ла,
30
ко - яш шул ук ка - ла, йол - дыз -







Вакыт җиле җәүһәр ташларның да
Җуя бара асыл төсләрен.
Яши-яши инде сүнә бара
Яшьлектәге кайнар хисләрең.
Яшьлектәге кайнар хисләрең.

Кушымта:
Ә ай шул ук кала,
Кояш шул ук кала,
Йолдызлар да кала —
Димәк, сөю кала!

Вакыт җиле горур кыяларның
Кыяфәтен тәмам үзгәртә.
Онытыла җанда олы кайгы,
Зур яралар бетә йөрәктә.
Зур яралар бетә йөрәктә.

Кушымта:
Ә ай шул ук кала,
Кояш шул ук кала,
Йолдызлар да кала —
Димәк, сөю кала!

Вакыт җиле кисә гомерләрне.
Бәлки, яшәү кирәк тә түгел?
Юк, ашыкма, җирдә яшәү өчен
Зур сәбәп бар әле, әй, күңел.
Зур сәбәп бар әле, әй, күңел.

Кушымта:
Ай бит шул ук кала,
Кояш шул ук кала,
Йолдызлар да кала —
Димәк, сөю кала!